БАЛАЛАР ЖУРНАЛЫ • ДЕТСКИЙ ЖУРНАЛ • CHILDREN'S MAGAZINE

№11.2016

Салават күпере

0+

ISSN 0868-4545



НОЯБРЬ

ДҮШӘМБЕ	СИШӘМБЕ	ЧӘРШӘМБЕ	ПӘНҖЕШӘМБЕ	ҖОМГА	ШИМБӘ	ЯКШӘМБЕ
	1 Сара Садыйкованың тууына 110 ел	2 Будильник көне	3 Күршеләр көне	4 Халыклар бердәмлеге көне	5 Йокы көне	6 Татарстан Республикасы Конституциясе көне
7 Беренче кар көне	8 Шаяннар һәм тапкырлар клубы көне	9 Сәяхәтләр көне	10 Россия полициясе көне	11 Спорт яратучылар көне	12 Куркынычсыз-лык белгечләре көне	13 Халыкара сукырлар көне
14 Социологлар көне	15 Россиядә армиягә чакырылучы-лар көне	16 Халыкара толерантлык көне	17 Дусларга хат язу көне	18 Кыш бабайның туган көне	19 Халыкара ирләр көне	20 Халыкара балалар көне
21 Халыкара телевидение көне	22 Итагатьле сүзләр көне	23 Музыкаль автомат туган көн	24 Көтелмәгән шатлыклар көне	25 Теләкләр кабул була торган көн	26 «Тыныч йокы, нәниләр!» тапшыруы туган көн	27 Әниләр көне
				28 Хисле кешеләр көне	29 Күз белән саубуллашу көне	30 Бөтендөнья филләр көне

© «Салават күпере», 2016 ел.

«SK» календарь

ЯҢА ЕЛДАН – ЯҢА БӘЙГЕ! БЕЗНЕҢ VKontakte битенә яраткан йорт хайваны белән төшкән фотоңны куй һәм тавыш җый!

МИН «САЛАВАТ КҮПЕРЕ»Н УКЫЙМ!



Әдилә, 2 яшь, Балтач.



Коля, 4 яшь, Лида, 13 яшь, Казан.



Мәдинә, 1 яшь, Казан.



Илзат, 7 яшь, Эльвина, 5 яшь, Казан.



Әлфинә, 6 яшь, Риана, 10 яшь, Азнакай.



Лениногорск шәһәренең 15 нче балалар бакчасы нәниләре.

АЙ-ҺАЙ

Абдулла Әхмәт

Кыш килде. Урамнарга ак юрган җәйде. Бакчаларга кар тулды, агачлар ак «чәчәк» аттылар.

Рәшитнең әнисенә эш артты. Ул тротуар чистартырга урамга чыкты. Рәшит тә тик торырга яратмый. Үзе кебек бәләкәй көрәк күтәрде дә кар көри башлады. Көрәге аның фанердан эшләнгән – җиңел.

Әй, рәхәт тә соң кышкы саф һавада кар көрәве! Эш һәм кыш Рәшитнең битен әнис алмасыдай кызартты. Бәләкәй борын бераз гына җебеп киткәләсә дә, аңа исе китми Рәшитнең. Бер тартып куя да җиңе белән сөртеп ала. Көрәвен белә.

Тротуардан кешеләр өзлексез агылып тора. Берәүләр – бу якка, икенчеләр – теге якка. Нишләптер, барысы да ашыгалар: эшләргә комачаулыйлар. Кайсыберсе Рәшиткә бәрелеп китә, кайберләре хәтта көрәккә дә басып узалар.

Баштарак Рәшитнең аларга бик үк исе китмәде. Эшендә булды, көри бирде. Менә бервакыт Рәшит көрәген күтәрә алмады. Караса, ни күрсен, бер абый аның көрәгенә баскан! Ачуы килде Рәшитнең. Аны-моны уйлап тормады:

– Йөрмәгез әле эш вакытында аяк астында чуалып! – дип кычкырды.

Абый дигәне бабай булып чыкты. Рәшит аның күзлеген күреп алды да:

– Күзлек киеп тә күзең күрми икән, әй! – дип өстәп куйды.

Бабай бер генә сүз әйтте:

– Ай-һай!..

Әйтте дә, кулындагы таягын селки-селки, китеп тә барды. Бабайның таягы Рәшитнең башына суккан кебек булды. Ә сүзе, сүзе бер генә булса да, күңелен әллә нишләтеп җибәрде: «Ай-һай!..»

Эш беткәч тә әле ул сүз Рәшитнең колак төбендә яңгырап, эчен пошырып торды: «Ай-һай!..»

– Әни, нәрсә дигән сүз ул «ай-һай»?

Әнисе аз гына уйлап торды да болай диде:

– «Ай-һай» мы? Син, малай, эш яратасың икән – әйбәт! Әниеңә булышуың да яхшы! Тик олыларга тупас мөгамәләң әйбәт түгел дигән сүз ул «ай-һай!».



КӨРӘК – ЛОПАТА – SHOVE [ШОВЕЛ]
ӨЗЛЕКСЕЗ – НЕПРЕРЫВНЫЙ – CONTINUOUS [КЭН'ТИНИУОС]
КОМАЧАУЛАУ – МЕШАТЬ – INTERFERE [ИНТЭ'ФИА]
ТУПАС – ГРУБЫЙ – RUDE [РУ:Д]
МӨГАМӘЛӘ – ОБРАЩЕНИЕ – APPEAL [Э'ПИ:Л]



Әдәбият тәнкыйтьчесе, шагыйрь, филология фәннәре кандидаты Мөдәррис Харис улы Вәлиев (әдәби тәхәллүсе – Салих Маннапов) 1953 елның 30 маенда Татарстанның Әлки районы Яңа Камка (Мәүләшә) авылында дөньяга килә. Шунда башлангыч, аннары күрше Алпар авылы мәктәбендә урта белем ала. Ул башлангыч мәктәптә укыганда ук шигырьләр яза, һәм аның исеме республиканың балалар-яшьләр матбугатында күренә башлый.

1971–1976 елларда Казан дәүләт университетының татар теле һәм әдәбияты бүлегендә укый. Монда студентларның атаклы «Әллүки» әдәби түгәрәген җитәкли. Бу чорда аның шигырьләре күмәк җыентыкларга керә, Казан радио һәм телевидениесе аша яңгырый.

1976 елдан алып бүгенгәчә Мөдәррис абыйның тормыш һәм хезмәт юлы татар матбугат дөньясы белән тыгыз бәйле. Өч елдан артык ул «Татарстан яшьләре» газетасында, соңрак «Казан утлары» журналында, Татарстан китап нәшриятында баш мөхәррир, 1992 елдан «Мәгариф-вакыт» милли китап нәшриятында директор булып эшли.



1989 елда ул «Балалар календаре» дигән исем белән әдәбинәфис һәм фәнни-популяр материаллардан зур җыентык төзеп чыгара. Шул ук елны Мөдәррис ага матбугат, мәгариф һәм әдәбият өлкәсендәге казанышлары өчен «Татарстан Республикасының атказанган мәдәният эшлеклесе» дигән мактаулы исемгә, ә 2003 елда М. Җәлил исемендәге Республика яшьләр премиясенә лаек була.

МЕС-МЕС ПЕСКӘЙ

Акбай да мияулый бүген:
Туган көне Пескәйнең.
Койрыгыннан гына була
белеп күпме үскәнен.
Табыны – телең йотарлык:
Монда сөт тә, тортлар да...
Тычкан да килмәкче булган
Пескәемне котларга, –
Тик Песинең дусты күреп,
Тычканның котын алган.

ТИН-ТИН ТИЕН

Тиен, тиен, тиенчек,
Йомры-йомшак төенчек.
Мендәр, юрган үзеңә,
Йокы төшсен күзеңә.
Төш артыннан төш чыгар,
Йоклаганда теш чыгар.
Уянсаң, тиз килермен,
Зу-у-ур чикләвек бирермен.

ДЕНЬ РОЖДЕНИЯ

В день рождения к котёнку
Заглянул Акбай – наш пёс:
Только по хвосту и видно,
Что котёночек подрос.
Угощают нынче щедро:
Молоко, сметана, торты...
Собралась и мышка в гости,
Высунула нос из норки.
Но не дремлет наш Акбай:
Мышь увидев, поднял лай.

Перевод Талии ШАРАФИЕВОЙ

КОЛЫБЕЛЬНАЯ

Мой бельчонок, мой сыночек,
Серый мягонький комочек.
Вот подушка, одеяло –
Спать тебе пора настала.
Сны волшебные придут,
За ночь зубки подрастут.
А проснёшься – я с тобой,
Дам тебе орех большо-о-ой.







PUSSY-PUSSY CAT

Doggy Akbay is meowing today
For good reason – Pussy Cat's birthday!
The birthday girl is swishing her tail,
Today she can do things her own way.
The table is full of yummy food:
There is milk and fish and cakes ...
Even the mouse was about to come
To wish Cat the best of the best, –
But Pussy Cat's friend saw the mousy
And scared the wits out of the guest.

Translation Dilyara Sharifullina

TICK-TICK SQUIRREL


Furry curly little squirrel,
You're a fluffy fuzzy lump.
Here's a blanket and a pillow –
Take a nice refreshing nap.
See a dream after a dream,
In your sleep show me your teeth.
If you wake up, I will bring
A big hazelnut as a treat.

РӘСЕМНӘРНЕ КИСЕП АЛ ҺӘМ ТУРЫ КИЛГӘН ШӘҮЛӘЛӘРГӘ ЯБЫШТЫР.



Җаваплар salavatkupere.com сайтында.

ЯФРАКЛАРНЫҢ ШӘҮЛӘЛӘРЕН ТАП. АЛАР НИНДИ АГАЧЛАРДАН КОЕЛГАН?



ГӨМБӘЛӘРНЕҢ ЭШЛӘПӘЛӘРЕ ӨСТЕНДӘ ЯЗЫЛГАН МИСАЛЛАРНЫ ЧИШ ҺӘМ ДӨРЕС КӘРЗИННӘРГӘ САЛ. БИРЕДӘ НИНДИ ГӨМБӘЛӘР БАР?

2+3




7-3



1+4



3+1



8-4









ГӨМБӘЛӘР

(Бармак уены)

БЕР, ИКЕ, ӨЧ, ДҮРТ, БИШ!

(Бармаклар учка җыелган, аларны чираттан турайтабыз)

БЕЗ ГӨМБӘГӘ БАРАБЫЗ!

(Кул чабабыз)

БУ БАРМАК УРМАНГА КИТКӘН,

(Чираттан бармакларны бөгәбез)

БУ БАРМАК ГӨМБӘ ТАПКАН,
БУ БАРМАК АНЫ ЧИСТАРТКАН,
БУ БАРМАК ТӘМЛЕ ИТЕП КЫЗДЫРГАН,
Ә БУ БАРМАК УТЫРГАН ДА АШАГАН,
ШУҢА КҮРӘ ТАЗАРГАН.



СИНЕҢ РӘСЕМНӘРЕҢНЕ ДӘ КӨТЕП КАЛАБЫЗ!



Риана АЕТОВА,
Азнакай,
10 яшь.



Ринат РӘКЫЙПОВ,
Әлмәт, 53 нче балалар
бакчасы, 5 яшь.



Эльвина АЛЕКСЕЕВА,
Кукмара, Село-Чура балалар
бакчасы, 5 яшь.



Элина НАГОРНОВА,
Бөгелмә, «Журавушка»
прогимназиясе, 7 яшь.



Илназ ЛАТЫЙПОВ,
Мөслим, Исәнсеф-Чишмә,
9 яшь.



Әдилә ГАРИПОВА, Казан,
5 нче гимназия,
2 нче сыйныф.



Зилә ФӘЙЗРАХМАНОВА,
Балтач, Балтач урта
мәктәбе, 10 яшь.



Камил СӘЛИМОВ,
Казан, 90 нчы гимназия,
3 нче сыйныф.



Элина МИФТАХОВА,
Әлмәт, 53 нче балалар
бакчасы, 6 яшь.

ӘНИЛӘРНЕ КАДЕРЛИК!

Ни өчен без әниләрне яратабыз? Куллары йомшак, тавышы ягымлы, үзе чибәр булган өчен генәме? Санап карыйк әле.

Тугыз ай буе әни безне йөрәк астында йөртә. Күңел җылысын бирә, сау-сәламәт тусын, гомере бәхетле булсын дип тели.

Без әнинең тәмле ашларын ашап, җан җылысын тоеп үсәбез. Берәр кая китсә, югалтабыз, борчыла башлыйбыз. Хәтта елыйбыз да.

Иң беренче тапкыр нәкъ әни кеше безне җитәкләп бакчага илтә. Аның белән иң беренче туган фикерләр, хыяллар белән бүлешәбез.

Мәктәп елларында әни безнең сердәшебез, киңәшчебез һәм иң якын дустыбызга әйләнә.

Әни таләпчән дә була, ачулана да. Әмма аңа үпкәләмибез, чөнки ул безгә яхшылык кына тели.

Әнинең елмаюы – минем өчен иң кадерлесе. Чөнки әнинең күңеле тыныч, йөзе шат булганда гына, барлык авырлыкларны, кайгыларны җиңеп була төсле.

Әни ул – өйнең көзгесе. Әниләрне кадерлик! Аларга сәламәтлек, гел шулай чибәр, яшь булып калуларын телик.

Мин әниемне бик яратам!

Әдилә ШӘМСИЕВА,
Актаныш, 1 нче мәктәп,
3 нче сыйныф.



ӘНИЕМ МИНЕ ЯРАТА

Әнием белән бергә,
Һәр көн күңелле үтә.
Иркәләп ул уята,
Чәчләремне тарата,
Тәмле итеп ашата,
Әнием мине ярата!

Әнием белән бергә
Һәр көн файдалы үтә.
Мәктәпкә ул озата,
Өй эшләрен аңлата,
Кирәк булса укыта,
Әнием мине ярата!

Әнием белән бергә
Һәр көн рәхәттә үтә.
Авыр чакта юата,
Кызык итеп уйната,
Әкият укып йоклата.
Әнием мине ярата!

Айзилә АЛИМОВА,
Казан, 171 нче мәктәп,
4 нче сыйныф.

ДУСКАЙ, ТИЗРӘК ЯНЫҢА ИПТӘШЛӘРЕҢНЕ ЧАКЫР! БЕРГӘЛӘП РӘХӘТЛӘНЕП УЙНАП АЛЫРГА ВАКЫТ. БИРЕДӘ СИН ШАКМАКЧЫК КҮРӘСЕҢ, АНЫ ИПЛӘП КЕНӘ КИСЕП АЛ ҺӘМ ЯННАРЫН БЕР-БЕРСЕНӘ ЯБЫШТЫР.

АННАРЫ ДУСЛАРЫҢ БЕЛӘН ШУНЫ ЧИРАТТАН АТЫГЫЗ ҺӘМ БИРЕМНЕ ҮТӘГЕЗ. ЯЗ, ҖӘЙ, КӨЗ ЯКИ КЫШ РӘСЕМЕ ЧЫКСА, БУ ЕЛ ФАСЫЛЫНЫҢ БЕРӘР БИЛГЕСЕН (СЫЙФАТЫН) ӘЙТЕГЕЗ ҺӘМ БЕР АДЫМ АЛГА БАРЫГЫЗ (МӘСӘЛӘН, УМЫРЗАЯ ЧӘЧӘГЕ ЯЗ ФАСЫЛЫН АҢЛАТА, АНЫҢ БЕР БИЛГЕСЕ – БӨРЕЛӘР ЧЫГУ). УЕН БЕРЕНЧЕ УЕНЧЫ ФИНИШКА КИЛЕП ҖИТКӘНЧЕ ДӘВАМ ИТӘ. УҢЫШЛАР!







…ФАСЫЛЛАРЫ







ФИНИШ







ХАЛЫК ИҖАТЫ



ШҮРКӘ БЕЛӘН ШАЛАЙ КҮПТӘН ТҮГЕЛ ТАТАР ХАЛЫК ИҖАТЫ ҮРНӘКЛӘРЕ БЕЛӘН ТАНЫШТЫ. БЕЛЕМНӘРЕН СЕЗНЕҢ БЕЛӘН ДӘ УРТАКЛАШАСЫЛАРЫ КИЛӘ.



КАЙБЕР ӘКИЯТ, ТАБЫШМАК, МӘКАЛЬ, ҖЫР, МӘЗӘК, ӘЙТЕМНӘРНЕ БЕР ГЕНӘ КЕШЕ УЙЛАП ЧЫГАРМЫЙ. АНЫҢ АВТОРЫ КҮП КЕШЕ БУЛЫРГА МӨМКИН. ӘЛЕГЕ ӘСӘРЛӘР БИК КҮПТӘННӘН ХАЛЫК ТАРАФЫННАН ИҖАТ ИТЕЛЕП, ТЕЛДӘН-ТЕЛГӘ КҮЧЕП КИЛӘ. ШУҢА КҮРӘ ДӘ АЛАРНЫ ХАЛЫК АВЫЗ ИҖАТЫ ДИП ЙӨРТӘЛӘР.

МӘКАЛЬ – ХАЛЫКНЫҢ ТОРМЫШ ТӘҖРИБӘСЕН ТУПЛАГАН КЫСКА ҺӘМ ТИРӘН МӘГЪНӘЛЕ ҖӨМЛӘ

Төшеп калган сүзләр урынына дөресләрен яз һәм мәкальнең мәгънәсен аңлат.

- Туган илем – . . . . . анам.
- Сәламәт тәндә . . . . акыл.
- . . кешене төзәтә, ялкаулык боза.
- Саф . . . . – тәнгә дәва.
- . . . . кешене бизи.

ТИЗӘЙТКЕЧ – ӘЙТҮ ӨЧЕН АВЫР БУЛГАН, БЕР-БЕРЛӘРЕНӘ ОХШАШ СҮЗЛӘРДӘН ТӨЗЕЛҮЧЕ ҖӨМЛӘ

Биредә ничә тизәйткеч яшерелгән? Дустың белән аларны әйтеп кара. Йә, кем өлгеррәк?

Үгезегез үзегезнеке,
Мөгезе үгезегезнеке.
Абагага бага-бага,
башым бәрдем баганага.
Җиләк, җиләк, җиләкләр,
Бик тиз тулмый чиләкләр.
Тулыр иде чиләге,
Юк бит аның җиләге.
Башта башлап таш баскыч
баскычына бастым.



ТАКМАК – БИЮ, КҮҢЕЛ АЧУ ӨЧЕН ӘЙТЕЛӘ ТОРГАН ӘСӘР

Такмакларда юллар буталган. Шуларны дөресләү һәм яттан сөйләргә өйрән.

- Болыт, болыт, килмә син,
Безнең юлны бүлмә син,
Мичтән бәлеш алыр идем,
Өйдә кунак бар, бар».

- Карга әйтә:
«Кар-кар, мичтә бәлеш бар, бар.
Син килгәч без куркабыз,
Өйгә кайтып китәбез.

- Ике песи суга бара,
Көянтә, чиләк асып.
Шул моңнарга чыдый алмый
Ата каз елап ята.

- Иртән торып тышка чыксам,
Кырмыска утын кисә.
Кара сарык биеп йөри,
Сыер чәбәкәй итә.
Ак әтәч курай тарта,
Тавык гармун уйната.
Ике тычкан карап кала,
Капка төбенә басып.



Җаваплар salavatkupere.com сайтында.

ТАБЫШМАК – СҮЗ УЙНАТЫП ӘЙТЕЛГӘН ҺӘМ ТӨП МӘГЪНӘСЕН УЙЛАП БЕЛЕРГӘ КИРӘК БУЛГАН НӘФИС СҮЗ

Табышмакларны укы һәм рәсемнәр арасында дөрес җавапны тап.

- Аннан башка тормыш юк.
- Ашка салсаң, тәм кертә,
  Борынга салсаң, төчкертә.
- Көмеш тәнле,
  Ите тәмле.
- Йөз кат кием, барысы да төймәсез.
- Әнәсе бар, ә тегә алмый.
- Тызлый да бызлый,
  Үпкән җире сызлый.
- Ашамый, эчми,
  Көне-төне эшли.



«ПЕСИ БЕЛӘН ТЫЧКАННАР»
Әлеге уенны дусларың белән җыелгач уйнап кара.

Бу уен почмак алыш уеннарының бер төре. Уенда биш бала катнаша. Уйнаучыларның берсе «песи» була. Калган дүртесе, «тычкан» булып, почмакта урын ала. Песи уртада тора. Тычканнар үз почмакларында торганда, ул аларга тимәскә тиеш. Тычканнар һәрвакыт урыннарын алмашырга дип йөгереп торалар. Шул чагында песи аларның берсен тотарга тырыша. Шуңа күрә урыннарын алмашырга теләгән тычканнар элек бер-берсенә күз белән яки кул белән ымлап, йә булмаса йөткереп, «Әйдә, урыннарны алмашабыз!» дигән серне белдерәләр.

Шул вакыт песи, башын аска игән, күзен йомган булып, астан гына аларны күзәтеп тора. Тычканнар, аннан көлеп, як-яктан такмаклыйлар:



Мияу-мияу мышнаган,
Мич башында кышлаган,
Бүген тычкан тотмаган,
Тотар иде йоклаган.

Песи-песи поскан,
Ике күзен кыскан,
Кысса безне тоталмый,
Тотар иде, җиталмый...

Шулай дип җырлашкан арада, алдан ымлашкан буенча, берсе икенчесенең почмагына таба чаба башлыйлар. Шул чагында песинең «күзләре ачыла», почмакка җиткәнче бер тычканны тотып ала. Кулына төшкән тычкан песи була, башта песи булган уенчы, буш почмакны алып, тычкан урынына баса. Уен шулай дәвам итә.

Диана Галимова

КАНАТЛЫ ТАЛАНТ







Мин – Диана Галимова, Казан шәһәре Вахитов районының 116 нчы лицеенда, 4 нче сыйныфта белем алам. Мәктәптә бары тик «5»ле билгеләренә генә укырга тырышам. Әле тагын «Идел» музыка мәктәбенә һәм «Созвездие» бию студиясенә йөрим. Шулай ук төрле бәйгеләрдә катнашып призлы урыннар алам. Буш вакытымда китап укырга, рәсем ясарга, шигырьләр язарга яратам. Рәсемнәремне сезгә дә тәкъдим итәм.

БӘЙРӘМ БҮЛӘГЕ



Дуслар, тиздән Әниләр көне җитә. Аларга нинди генә матур теләкләр теләсәк тә, аз булыр кебек. Ә әниләребез шатлансын өчен күп кирәкми – балалары исән-сау булып, уңышлары белән куандырсалар, алар бик бәхетле. Озын гомер, нык сәламәтлек, шатлык-куанычлар телибез, сезгә, кадерле кешеләребез! Ә бүген, әйдәгез, әниләребезгә матур кыса ясап бүләк итик.


КИРӘКЛЕ ӘЙБЕРЛӘР:

катыргыдан киселгән 10 Х 10 см үлчәмле 2 квадрат, 2 төсле җеп, җилем.



1 Квадратларны бер-берсенә куеп ябыштырабыз.

2 Башта бер җеп белән һәрбер аралыкны 5 кат урап чыгабыз.



3 Җепләрне чиратлаштырып барабыз.

4 Шул рәвешле кыса килеп чыкканчы дәвам итәбез. Кысага фото яки чәчәкләр бәйләме рәсемен урнаштырырга була.

Авторы: Халидә Мәсхүт кызы НУРИЕВА, Арча районы Кысна башлангыч мәктәбе укытучысы.

Зиннур ХӨСНИЯР

Әни буласым килә

Бәби буласым килми,
Килә әни буласым.
Еламыйча аның кебек
Ашка суган турыйсым.




Бәби булудан туйдым,
Үсәсем килә тизрәк.
Әти әйтә: «Үсү өчен
Ботка ашарга кирәк».

Ашамыйм боткасын да,
Үсәм мин шулай гына.
Курчакларым бәби булыр,
Мин әни болай гына.



Менә бит минем кызларым:
Айгөл, Зилә, Лилия.
– Чү, туктагыз, ник елыйсыз?
Лилиягә кем тия?



Тамаклары ачкандыр,
Хәзер ботка пешерәм.
Чәчегезне үрермен,
Ким булмагыз кешедән.



Әтәч кычкырды күптән
Җыеныгыз тизрәк.
Бакча иртүк ачыла,
Барып җитәргә кирәк.

Киттек чыгып урамга,
Бер-бер артлы барабыз.
Ачуланам, тузынам,
Нигә артта каласыз?!



Каян яңгыры яуган –
Күлләвекләр юлымда.
Балаларым пычрана бит,
Кечерәкләр – кулымда.

Бигрәк ерак бакчасы,
Кайчан барып җитәрбез.
Шул араны тәпиләп
Алҗыдык без, ардык без.

Кызлар бакчада калды,
Өйгә кайттым тизрәк.
Тәртипсезлек бит анда,
Җыештырырга кирәк.

Ашарга да пешерәсе,
Керләрне юасы бар.
Иң авыры, елый-елый,
Суганын турыйсы бар!..


Тагын күп эшләр көтә,
Чүпләп бетермәс тавык.
Юганны көтеп тора
Бер өем табак-савыт.

Абау, билем дә авырта,
Аякларым бик арды.
Очып кына йөрсәм дә,
Ярты эш торып калды.

Әни, әни, әни дим,
Буласым килми әни.
Хаталандым бугай мин,
Ялгыштым бит әллә ни.

Кызларым да курчак булсын:
Айгөл, Лилия, Зилә.
Әни булу авыр икән,
Бәби буласым килә...





SKWORDSKWORDSKWORDSKWORDSKWORDSKWORDSKWORD



ИР-АТ АВЫЛ КИЕМЕ

Дусларым, Шалай белән сезне авыл ир-ат киеме белән таныштырырга уйладык әле. Хатын-кызларның киеме кебек, ир-егетләрнең киеме дә көн буе эш башкару өчен уңайлы булган. Егетләр дә күлмәк өстеннән алъяпкыч кигән. Алъяпкыч агартылган киндердән яки биздән тегелгән. Хатын-кызларныкыннан аермалы буларак, алъяпкычка бизәкләр чигелмәгән, бары тик бер төрле тукымадан гына тегелеп, киемне пычратудан саклаган. Авыл җирендә элек-электән киң кулланылган кием – ул бишмәт. Карт бабайларныкыннан аермалы буларак, урта яшьтәге ир-егетләрнеке кыскарак булган. Җәй көне киндер чолгау өстеннән чабата кигәннәр. Яшь киленнәр булачак ирләренә аяк чолгауларының баш-башларын матурлап чигеп бүләк иткәннәр. Мондый чолгаулар бары тик туй көнендә бер генә тапкыр киелгән, ә аннары кадерле ядкәр итеп сандыкта саклана торган булган. Ә ишегалдында, утарда эшләгәндә җиңел салына торган, салгач болдырда калдырыла торган галошлар кигәннәр. Өй эчендә кияр өчен оек яки махсус җиңел, күн аяк киеме кулланганнар. Егетләрнең элек-электән яратып киеп йөри торган баш киеме түбәтәй булган. Ә җәй көннәрендә кырда эшләү өчен уңайлы баш киеме булып түбәтәй өстенә киелгән түгәрәк һәм кырлары түбәнгә таба салынып торган ак киез эшләпә саналган.

Руфия МӨХЕТДИНОВА, Татарстан Республикасы Милли музееның матбугат үзәге җитәкчесе.





№11 (320) – 2016

Журнал 1990 елның март аеннан бирле чыга.
Журнал выходит с марта 1990 года.

Директор
Зиннур ХӨСНИЯР
(Зиннур Зыятдин улы ХӨСНЕТДИНОВ)

Баш мөхәррир
Зилә ЯЗ
(Зилә Зиннур кызы ХӨСНЕТДИНОВА)

Баш мөхәррир урынбасары
Гүзәл ЗИННӘТУЛЛИНА

Мөхәррирләр
Гөлназ ЯРМИЕВА
Алсу НИЗАМИЕВА

Баш рәссам
Әлфия ЙОСЫПОВА

Компьютер дизайны
Мөнирә КУЗИЕВА

0+ Мәктәпкәчә яшьтәге һәм кече яшьтәге мәктәп балалары өчен.

«Салават күпере» журналының компьютер үзәгендә җыелды һәм төсләргә бүленде.

Басарга кул куелды 20.10.16 ел.
Кәгазь форматы 60х90 1/8.
Гарнитура – PT Sans.
Офсет ысулы белән басыла.
Заказ: М-2782. Тираж: 8200 данә.

Килгән хатлар, кулъязмалар һәм рәсемнәр рецензияләнми, авторларга кире кайтарылмый.

Почта гаебе белән журнал өегезгә килеп җитмәсә, түбәндәге телефон белән газета-журналлар экспедициясенә шалтырата аласыз: (843) 562-10-66.



Журнални гамәлгә куючы – «ТАТМЕДИА» АҖ.

Татарстан республикасы матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы ярдәмендә чыгарыла.


Бәясе ирекле.
ЯЗЫЛУ ИНДЕКСЫ:
Татарстанда – П2339
Россиядә – 73953.

Тышлыкта Әлфия Йосыпова рәсеме.

Нәшер итүче: «ТАТМЕДИА» АҖ, 420097, Казан, Академическая ур., 2 й.
Редакция адресы: 420066, Казан, Декабристлар ур., 2 й., 10 кат.
Тел.: (843) 222-05-46.
E-mail: salavatkupere@mail.ru
Сайт: www.salavatkupere.com

Элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә күзәтчелек итү буенча федераль хезмәт тарафыннан ФС77-54277 номеры белән 2013 елның 24 маенда теркәлде.

«ТАТМЕДИА» АҖ филиалы «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылды.
Адресы: Казан шәһәре, Декабристлар ур., 2 й.





Күлмәк




Камзул


Чалбар


Эшләпә


Чабата